ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НОВОТРОИЦК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
КАРАРЫ

17 октябрь, 2024 ел. № 11

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новтроицк авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Советы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында 2019 елның 08 ноябрендәге 41/1 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 31 октябрь көнне 2024 елның сәгать 18.00 Новотроицк авылында Березовая, Садовая, Зеленая, Тополиный тыкрыгы, Центральная урамнарында 23-94 санлы үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 31 октябрь көнне 2024 елның сәгать 19.00 Новотроицк авылында Новая, Новоселов, Молодежная, Солнечная, Придорожная, Луговая, Цветочная, Полевая урамнарында, үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 01 ноябрь көнне 2024 елның сәгать 18.00 Новотроицк авылында Ленин, Школьная, Овражная, Весенняя, Центральная урамнарында 1-22 санлы үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. 01 ноябрь көнне 2024 елның сәгать 19.00 Новотроицк авылында Челнинская, Тукай к-с, Жукова к-с урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының дүртенче этабын билгеләргә.
5. 01 ноябрь көнне 2024 елның сәгать 20.00 Новотроицк авылында Сармановкая, Юбилейная, Автозаводская, Космонавтов, Энергетиков, Монтажная, Береговая, Ботаническая, Радужная, Тихая, Уютная, Ближняя, восьмого Марта, Дачная, Загородная, Июньская, Казанская, Летняя, Магистральная, Малая, Студенческая, Степная, Физкультурная, Сельская урамнарында, Беренче квартал юл, Икенче квартал юл үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының бишенче этабын билгеләргә.
6. Халык җыенын уздыру өчен Новотроицк авыл яшәүчеләрнең исемлеге аерым бүленә, сайлау тәртибе территориаль билге буенча башкарылырга тиеш.
7. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2025 елда яшәү урыны буенча Новотроицк авыл җирлеге Новотроицк авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы

студентларга, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә әлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Новотроицк авылында вак таш сатып алу);

- урам яктырту эшләрен башкару (электроматериаллар сатып алу, Новотроицк авылында урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Новотроицк авылында мафлар урнаштыру).»

«ӘЙЕ» «ЮК».

8. Халык җыенын беренче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Новотроицк авыл, Үзәк урамы, чиркәү янында. адресы буенча үткәрергә.

9. Халык җыенын икенче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Новотроицк авыл, Сельская урамында үткәрергә.

10. Халык җыенын өченче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Новотроицк авыл, Ленин урамы, күп фатирлы йортлар ишегалдында үткәрергә.

11. Халык җыенын дуртенче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Новотроицк авыл, парк «Солнечный» ( мәчеть каршында) үткәрергә.

12. Халык җыенын бишенче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Новотроицк авыл, Береговая урамы адресы "Пятерочка" кибете янында үткәрергә.

13. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл жирлеге башкарма комитеты билгеләргә.

14. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

15. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

16. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Новотроицк авыл җирлеге Башлыгы Д.М. Габделхаева